**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 июнь 2014 ел № 7-9/т

***Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы ААҖ “Норлат АТП” тарафыннан хезмәт күрсәткән, шәһәряны җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы ААҖ “Норлат АТП” тарафыннан хезмәт күрсәткән, шәһәряны җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны, әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.
2. “Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы шәһәряны җәмәгать автомобиль транспортында ААҖ “Норлат АТП” тарафыннан пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” 27.08.2010 № 7-16/т Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарын үз көчен югалткан дип исәпләргә.
3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
06 июнь 2014 ел № 7-9/т

## Татарстан Республикасының Норлат муниципаль районы ААҖ “Норлат АТП” тарафыннан хезмәт күрсәткән, шәһәряны җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| № п/п | Уңайлык исеме | Үлчәү берәмлеге | Максималь чик тариф (ӨБС исәпкә алынмаган) |
|---|---|---|---|
| 1 | Пассажирларны автобуста алып бару | руб./пасс./км | 2,00 |
| 2 | Автобуста бер урын багажны алып бару | руб./км | 0,30 |